ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
КАРАКАШЛИНСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ ЮТАЗИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Сирин Батыршин, д.33,
с.Кәрәкәшле, 423961

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ КӘРӘКӘШЛЕ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Сирин Батыршин урамы, 33 йорт,
Кәрәкәшле авылы, 423961

Тел.:(85593) 4-21-34, факс:4-21-21, e-mail: Karak.Utz@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**№ 14** **29 апрель 2025 ел.**

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының "Кәрәкәшле авыл җирлеге" муниципаль берәмлегенең балалар мәйданчыкларын, уен һәм спорт җиһазларын тикшерү буенча комиссиясе составын раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Балалар уен мәйданчыкларын җиһазлау. Эксплуатация вакытында куркынычсызлык. Гомуми таләпләр” ГОСТ Р 52301-2013 нигезендә, "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Кәрәкәшле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Кәрәкәшле авыл җирлеге Башкарма комитетының 2025 елның 29 нчы апрелендәге 13 санлы карары белән, балалар гомерен һәм сәламәтлеген саклау, гражданнарның уңайлы һәм куркусыз яшәвен тәэмин итү, балалар уен мәйданчыкларын төзекләндерү объектларының, җиһазларның һәм каплауның сакланышын тәэмин итү максатларында, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Кәрәкәшле авыл җирлеге территориясендә урнашкан балалар мәйданчыкларыннан (уен, спорт мәйданчыкларыннан) файдалану куркынычсызлыгы максатларында Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Кәрәкәшле авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР ИТӘ:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Кәрәкәшле авыл җирлеге территориясендә урнашкан муниципаль балалар мәйданчыкларын (уен, спорт мәйданчыкларын) тикшерү буенча комиссия төзергә.
2. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Кәрәкәшле авыл җирлеге территориясендә урнашкан муниципаль балалар мәйданчыкларын (уен, спорт мәйданчыкларын) тикшерү буенча комиссия составын расларга (1 нче кушымта).
3. Әлеге карар Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Кәрәкәшле авыл җирлеге рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының «Рәсми Татарстан» бердәм порталының «Интернет» мәгълүмат-

телекоммуникация челтәрендә урнаштыру юлы белән халыкка игълан ителергә тиеш: http://jutaza.tatarstan.ru/.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Кәрәкәшле авыл җирлеге
Башлыгы Урынбасары: Э. Ф. Исхакова

Кәрәкәшле авыл җирлеге
Башкарма комитетының
29.04.2025 ел, № 14 карарына
1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының "Кәрәкәшле авыл җирлеге" муниципаль берәмлегенең балалар мәйданчыкларын, уен һәм спорт җайланмаларын тикшерү буенча комиссия составы

| | |
|---|---|
| Комиссия рәисе | Э.Ф.Исхакова – Кәрәкәшле авыл җирлеге Башлыгы Урынбасары |
| Секретарь комиссии: | Э.Ф.Ямалиева - Кәрәкәшле авыл җирлеге Башкарма комитеты секретаре |
| Комиссия әгъзалары | А.Н.Захаров- Ютазы муниципаль районының инфраструктура үсеше башлыгы (килешү буенча) |
| | Р.А.Галлямова- "Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге" МКУ башлыгы (килешү буенча) |